# КАРАР

26 ноябрь 2020 ел №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авы җирлегенең Кәркәүч авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 25, 26 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авылы җирлегенең Кәркәүч авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан) тыш, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлар 2021 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә риза булырсызмы?

- М. Җәлил һәм Яшеллек урамнары буенча юлга вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Кәркәүч авылы урамнарын яктырту лампалары сатып алу һәм урнаштыру ;
-Кәркәүч авылында юлларны кардан чистарту; проект-смета документациясен эшләү;
- М. Җәлил урамы буенча күпер кырларында саклагыч коймалар сатып алу һәм урнаштыру;
- Кәркәүч авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне койма белән әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү;
- видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган ,җыенда катнашучылар исемлегенә 237 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 125.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 125 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
"Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кәркәүч авыл җирлегенең Кәркәүч авылы гражданнар җыенын узган дип таныырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2. Сорау буенча карарны танырга: «2021 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Кәркәүч авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада белем алучы 1 төркем инвалидлардан, укучы һәм студентлардан (курсантлардан) тыш, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән, 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә килешеп торасызмы:
- М. Җәлил һәм Яшеллек урамнары буенча юлга вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Кәркәүч авылы урамнарын яктырту лампалары сатып алу һәм урнаштыру ;
-Кәркәүч авылында юлларны кардан чистарту; проект-смета документациясен эшләү;
- М. Җәлил урамы буенча күпер кырларында саклагыч коймалар сатып алу һәм урнаштыру;
- Кәркәүч авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлне койма белән әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру; проект-смета документациясен эшләү;
- видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы М.Ф.Зәйнетдинов